## ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районынын «Салагыш авыл җирлегенең» муниципаль берәмлеге Салагыщ торак пунктында гражданнар жыены нәтиҗәләре турында

**28.10.2022** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның «28» октябре 15 сәгать 00 минутта һәм 17 сәгать 00 минутта узган гражданнар жыены беркетмәсе төзелде:

"2023 елда Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Салагыш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1000 сум куләмендә узара салым акчалары жыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

-Салагыш торак пункты территориясендә су насослары, сууткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен сантехник материаллар сатып алу, су скважинасы казу;

-Салагыш торак пункты урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар, материаллар сатып алу һәм алыштыру;

-Салагыш торак пункты урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу);

-Салагыш торак пункты К.Маркс урамы өчен вак таш сатып алу һәм аны җәю

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар жыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган жыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар жыенында катнашучы 316 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны-172 кеше, бу 54% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар жыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар жыенынңда 172 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен жыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар жыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салауш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Салагыш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салауш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Салагыш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1500 сум куләмендә узара салым чаралары җыюны кертүгә.

3.Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Салагыш торак пунктында су насослары, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен сантехник материаллар сатып алу( скважиналар бораулау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

-Салагыш авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар, материаллар сатып алу һәм алыштыру;

-Салагыш урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу);

-Салагыш авылында К.Маркс урамы өчен вак таш сатып алу һәм аны җәю.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.agryz.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче М.М. Мөхәммәдиев

Совет Салаушского сельского поселения
Салагыш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002431